Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Чэчэкле авыл җирлегенең торак пунктында 2025 елда
гражданнардан үзара салым кертү турында:

21.11.2024 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чэчэкле авыл җирлегендә гражданнар җыены

карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чэчэкле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрергә:

1) Чэчэкле торак пунктында Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (энергияне саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

2) Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (су җыю башняларын, скважиналарын койма белән әйләндереп алу, (шартнамә буенча материал сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)) Чэчэкле торак пунктында;

3) Чэчэкле торак пункты территориясен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чаптыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

4) Чэчэкле торак пунктында ремонтлау, коймалар урнаштыру, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, җәй көне территорияне карап чыгу, чүп-чардан, куаклардан чистарту, (бензопила сатып алу, триммер өчен запас частьләр сатып алу);

5) Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүп-чарларны бетерү (рөхсәтсез чүп-чарларны бетерү шартнамәсе буенча эшләр һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү, (каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү өчен контейнерлар сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) Чэчэкле торак пунктында.».

3. Әлеге карарны Чэчэкле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерү, Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ spasskiy.tatarstan.ru) бастырып чыгару, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгару.

Халык җыенында рәислек итүче,
Спас муниципаль районының
Чэчэкле авыл җирлеге башлыгы: Р.Р. Фәисханов